ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧИРМЕШӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

15 февраль 2019 ел №113

Апас муниципалл районы Чирмешән авыл җирлеге территориясендә авыл хуҗалыгы хайваннарын тоту кагыйдәләренең 4 пункты үз көчен югалткан дип тану турында

"Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы авыл җирлеге Советының 2013 елның 5 июненнән 34 номерлы “Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге территориясендә авыл хуҗалыгы хайваннарын тоту кагыйдәләрен раслау турында” карары белән расланган Апас муниципаль районы Чирмешән авыл җирлеге территориясендә авыл хуҗалыгы хайваннарын тоту кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 бүлекнең 4 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чирмешән авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Чирмешән авыл җирлеге башлыгы А.Т.Зиннатуллин